Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Ислəй авыл җирлеге Советы

2024 елның 27 ноябре № 48/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге территориясендə туристлык салымын билгелəү һəм гамəлгə кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 33.1 бүлеге, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һəм икенче өлешлəренə үзгəрешлəр кертү турында» 2024 елның 12 июлендəге 176-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендə туристлык эшчəнлеге нигезлəре турында» 1996 елның 24 ноябрендəге 132-ФЗ номерлы Федераль закон һəм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге Уставы нигезендə, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислəй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге территориясендə туристлык салымын билгелəргə һəм гамəлгə кертергə.

2. Салым ставкаларын салым базасыннан килəсе күлəмдə билгелəргə:
1) 2025 елда - 1 процент;
2) 2026 елда - 2 процент;
3) 2027 елда - 3 процент;
4) 2028 елда - 4 процент;
5) 2029 елдан башлап – 5 процент.

3. Салым түлəү тəртибен Россия Федерациясе Салым кодексының 418.8 статьясы нигезендə билгелəргə.

4. Вакытлыча яшəү буенча хезмəт күрсəтүлəрнең бəясе салым базасына кертелми торган физик затлар категориялəре Россия Федерациясе Салым кодексының 418.4 статьясының 2 пункты белəн билгелəнгəн.

5. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге территориясендə туристлык салымын исəплəү тəртибе Россия Федерациясе Салым кодексының 418.7 статьясы нигезендə билгелəнə.

Россия Федерациясе Салым кодексының 418.7 статьясы нигезендə исəплəнгəн туристлык салымы суммасы 100 сумның тапкырлавы һəм яшəү тəүлеге саны буларак исəплəнгəн минималь туристлык салымы суммасыннан кимрəк булган очракта, туристлык салымы суммасы минималь туристлык салымы күлəмендə билгелəнə.

6. Əлеге карарны массакүлəм мəгълүмат чараларында һəм (яисə) «Татарстан Республикасының рəсми хокукый мəгълүмат порталы» нда (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һəм Чистай муниципаль районының «Интернет» мəгълүмат-коммуникация челтəрендəге рəсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

Ислəй авыл җирлеге
башлыгы В.П. Чернышев